ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**« 18 » декабрь 2017 ел** **№ 1431**

**Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.12.2013 ел, № 1146 Карары белән расланган күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча региональ программаның кыска сроклы планына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы һәм «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Арча районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.12.2013 ел, № 1146 Карары белән расланган күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча региональ программаның кыска сроклы планын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Татмедиа» ААҖ филиалы «Арча хәбәрләре газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында ( )pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппаратының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.В. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.Ә.Галимуллин

Арча муниципаль районы
башкарма комитетының
“____” ___________2017ел, № ____
карарына1 нче кушымта

**2017-2019 елларда Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 31.12.2013 ел, № 1146 Карары белән расланган күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча региональ программаның кыска сроклы планы**

## I. Гомуми нигезләмәләр

2017-2019 елларда Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 31.12.2013 ел, № 1146 Карары белән расланган күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча региональ Программаның әлеге кыска сроклы планы (алга таба – кыска сроклы план, озак сроклы программа) Россия Федерациясе Торак кодексы, «торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 21.07.2007 ел, № 185-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 25.06.2013 ел, № 52-ТРЗ Татарстан һәм (яки) эшләрнең планлаштырылган төрләрен төгәлләштерү, капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт, муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү.

## II. Кыска сроклы планның төп максатлары һәм бурычлары

Төп максатлары:

Арча муниципаль районында торак фондын саклау һәм торгызу;

гражданнар яшәве өчен имин һәм уңайлы шартлар тудыру;

торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруны стимуллаштыру;

торак фонды белән идарә итүнең нәтиҗәле механизмнарын формалаштыру.

Кыска сроклы планның төп бурычлары:

торак фондының сакланышын тәэмин итү һәм кулланучанлык сыйфатын арттыру;

торак фондын билгеләнгән нормативларга туры китерү;

торак фондының тузу дәрәҗәсен киметү;

ресурсларны саклау технологияләрен кертү.

## III. Кыска сроклы план чаралары исемлеге

1) оештыру чаралары:

капиталь ремонт эшләрен үткәрү, кирәкле эш күләме, материалларның бәясе, ремонтны финанслау тәртибе һәм капиталь ремонт үткәрүнең башка шартлары турында карарлар кабул итү өчен бина милекчеләренең җыелышларын билгеләнгән тәртиптә үткәрү;

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе белән тикшерү актларын һәм җитешсезлек исемлекләрен килештереп, күпфатирлы йортларны тикшерү;

капиталь ремонт объектларына проект алды, беренчел-рөхсәт һәм проект документларын эшләү һәм әлеге документацияне төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча Федераль агентлыкның Татарстан Республикасы буенча төзелеш һәм төзелеш материаллары сәнәгатендә бәя кую федераль үзәге филиалы белән килештерү;

капиталь ремонт үткәрү эшләрен башкару өчен билгеләнгән тәртиптә подрядчы оешмаларны сайлап алу;

Кыска сроклы планны финанс белән тәэмин итү.

2) капиталь ремонт үткәрелергә тиешле күпфатирлы йортлар исемлегенә яраклаштырып, кушымта нигезендә капиталь ремонтлау буенча техник чаралар.

3) Кыска сроклы планга мониторинг:

Кыска сроклы план чараларының үтәлешен, аны тормышка ашыруга бүлеп бирелгән финанс чараларын куллануны тикшереп тору;

анализ һәм бәяләү нәтиҗәләре

2017-2019 елларда Арча муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын гамәлгә ашыруның кыска сроклы планын №1, №2, №3 таблицасы нигезендә үтәүнең планлаштырыла торган күрсәткечләре.

## IV. Кыска вакытлы планны ресурслар белән тәэмин итү

Кыска вакытлы планны финанслау чыганагы-торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фонды, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет, бина милекчеләре акчалары.

2017, 2018, 2019 елларга КФЙ капиталь ремонтлау чараларын финанслауның финанс чаралары күләме:

- 2017 ел-16267190,31 сум.;
- 2018 – 20571072,12 сум
- 2019- 15350433,44 сум

Программаны финанслау күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен финанс чараларының ихтыяҗы күләменнән чыгып башкарыла.

**Капиталь ремонтны үткәрү һәм финанслау күләме**
**2017 елга күпфатирлы йортлар**

1 нче таблица

| Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча эш төрләре | Капиталь ремонт үткәрү күләме, бер.изм. | Капиталь ремонт үткәрүгә финанс чараларының ихтыяж күләме, мең сум. |
|---|---|---|
| Металл түбәне ремонтлау, кв. м | 2460,00 | 2789654,20 |
| Фасадларны җылыту, кв. м | 3436 | 10906654,44 |
| Фасадларны ремонтлау, кв. м | 195,00 | 433128,09 |
| Подъездларны ремонтлау, пог.м | 1933,00 | 1491509,09 |
| Техник паспортлар ясау, бер. | 7 | 101000,00 |

**Капиталь ремонтны үткәрү һәм финанслау күләме**
**2018 елга күпфатирлы йортлар**

2 нче таблица

| Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча эш төрләре | Капиталь ремонт үткәрү күләме, бер.изм. | Капиталь ремонт үткәрүгә финанс чараларының ихтыяж күләме, мең сум. |
|---|---|---|
| Фасадларны җылыту, кв. м | 4760,06 | 16654948,06 |
| Подъездларны ремонтлау, пог.м | 3995,50 | 3313026,78 |
| Техник паспортлар ясау, бер. | 8 | 106000,00 |

**Капиталь ремонтны үткәрү һәм финанслау күләме**
**2019 елга күпфатирлы йортлар**

3 нче таблица

| Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча эш төрләре | Капиталь ремонт үткәрү күләме, бер.изм. | Капиталь ремонт үткәрүгә финанс чараларының ихтыяж күләме, мең сум. |
|---|---|---|
| Металл түбәне ремонтлау, кв. м | 2366,00 | 6373890,05 |
| фасадларны җылыту, кв. м | 2203,00 | 5930476,00 |
| фасадларны ремонтлау, кв. м | 440,00 | 1512798,76 |
| Подъездларны ремонтлау, пог.м | 1480,68 | 998790,00 |
| Техник паспортлар ясау, бер. | 6 | 90000,00 |

Кыска сроклы планны гамәлгә ашыру барышында аерым чаралар, финанслау күләмнәре һәм чыганаклары ел саен торак-коммуналь хуҗалыкны реформалауга ярдәм фонды, Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле

бюджет акчаларын бүлү, муниципаль берәмлек тарафыннан «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында» 21.07.2007 ел, № 185-ФЗ Федераль законның 14 статьясында каралган финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәү нәтиҗәләре буенча төзәтмәләр кертелергә мөмкин.

## V. Кыска сроклы планны тормышка ашыру механизмы

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башкарма комитеты:

региональ программаны тормышка ашыру буенча кыска вакытлы (еллык) муниципаль планнарны формалаштыра һәм министрлыкка җибәрә;

Министрлыкка муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларының үтәлешен раслаучы норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм башка документлар тапшыра;

җирле бюджет акчаларын федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм торак законнары нигезендә әлеге Кыска сроклы планда билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт эшләрен финанслашуга күчерә;consultantplus://offline/ref=91DDFDC8BCC0F1653A493104187DE6BEA4AF9695519F81507BBBA9050417ABN

региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләргә техник заказчы функцияләрен башкара;

башкарылган эшләр актларын, капиталь ремонт эшләрен кабул итү актларын, күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау өчен расланган чыгымнар сметасында каралмаган акчадан файдалану очракларыннан тыш, шулай ук ул арткан очракта, килештерә;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча эшләр башкаруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тота;

Министрлык билгеләгән тәртиптә тиешле муниципаль берәмлек буенча Кыска сроклы планны (шул исәптән күпфатирлы йортларда торак һәм торак булмаган биналар мәйданнары буенча мәгълүматлар) гамәлгә ашыру максатларында мәгълүматлар базасын барлыкка китерәләр һәм актуаль хәлдә тота;

Фондка хисап формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне Министрлыкка һәм Кыска сроклы планның башка башкаручыларына тапшыра.

УО, ТСЖ:

тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә җитешсезлек исемлекләрен, башкарылган эшләр актларын һәм (яки) хезмәтләр күрсәтүне килештерә;

региональ оператор белән түләү документларын формалаштыруга һәм капиталь ремонт өчен кертемнәр буенча милекчеләрнең ай саен исәпләнүен һәм түләүләрен региональ оператор счетына күчерүне тәэмин итүгә шартнамәләр (килешүләр) төзи;

дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алу белән проект документларын әзерләүне тәэмин итә;

торак милекчеләренә капиталь ремонт башлану вакыты, кирәкле исемлек һәм хезмәтләр күләме, аларның бәясе, күпфатирлы йорттагы гомуми милекне капиталь ремонтлауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр кертә;consultantplus://offline/ref=91DDFDC8BCC0F1653A493104187DE6BEA4AF9795559881507BBBA9050417ABN

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау мәсьәләләре буенча милекчеләрнең җыелышларын оештыра;

капиталь ремонт объектларына керүне гамәлгә ашыра;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауны вакытында һәм сыйфатлы башкаруларын, шулай ук капиталь ремонттан соң күпвфтирлы йортларны файдалануга алуны, капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән контрольдә тота.

Фатир хуҗалары

тикшерү актларын, капиталь ремонт эшләре күләменә карата җитешсезлек исемлекләрен килештерәләр;

күпфатирлы йортларны үз вакытында һәм сыйфатлы ремонтлауны контрольдә тотуда, шулай ук капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән аларны файдалануга алуда катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча Кыска сроклы план һәм подряд килешүе белән билгеләнгән вакыт эчендә эшләрне башкаруны тәэмин итәләр;

КС-2, КС-3 формалары буенча башкарылган эшләр актларын формалаштыралар;consultantplus://offline/ref=91DDFDC8BCC0F1653A493104187DE6BEA4A995945097DC5A73E2A50703745F47EE14E41F718A471EA0Nconsultantplus://offline/ref=91DDFDC8BCC0F1653A493104187DE6BEA4A995945097DC5A73E2A50703745F47EE14E41F7189411EA1N

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкарган өчен җаваплы;

объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

подряд килешүендә каралган башка эшләрне башкаралар.

Техник заказчы функцияләрен башкаручы оешмалар:

проект документларын, шул исәптән сметаны әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонт үткәрү вакытында төзелешкә контрольлек итәләр;

башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашалар, башкарылган эшләр актларын килештерәләр;

объектны кулланышка кабул итүдә катнашалар, объектны кабул итү актын килештерәләр;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкарган өчен җаваплы;

проект оешмасыннан проект-смета документларын кабул итәләр;

күпфатирлы йортта күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча башкарылган эшләрне кабул итү актына кул куйганнан соң 10 көн эчендә әлеге күпфатирлы йорт белән идарә итүче затка күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау турындагы документларның күчермәләрен (шул исәптән, проект, смета документлары, хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) капиталь ремонт буенча эшләр башкару турындагы шартнамәләрнең күчермәләрен) һәм капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка документлар тапшыралар, финанс документларыннан тыш;

техник заказчының законнарда каралган башка функцияләрен гамәлгә ашыралар.

Филиал ОАО «Татмедиа» «Редакция газеты «Арча хәбәрләре» («Арский вестник»), Республиканское агентство по печати и массовым коммуникациям "Татмедиа" осуществляет регулярное освещение хода реализации мероприятий Краткосрочного плана.

Кыска сроклы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау "торак фонды мониторингы"бердәм мәгълүмат продуктында тормышка ашырыла.

## VI. Подрядчы оешмаларны сайлап алу тәртибе капиталь ремонт эшләрен башкару өчен күпфатирлы йортларның гомуми милеген

Подрядчы оешмалар «күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләрне башкару өчен подрядчы оешмаларны җәлеп итү тәртибе һәм күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлек алып баручы махсуслаштырылган коммерцияле булмаган оешма функцияләрен үтәү максатларында товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу тәртибе турында»Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 1 июлендәге 615 номерлы карары нигезендә региональ оператор тарафыннан сайлап алына.